*Зыялы кыз — ил күрке!*

# КЫЗЛАР ИЛЕ

**Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназиянең «Нур» балалар оешмасы газетасы**

**6 +**

**№ 12 (13)**
**март**
**2022 ел**

# Бүгенге санда:

- ***Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясе “9 ел бергә!”*** *2-3 битләр*
- ***“Көмеш беләзекле чыгарылыш укучылары”*** *4 бит*
- ***“Энҗе калфак” сәхифәсендә - Ясинә Зәбирова*** *5 бит*
- ***«Мөһаҗирләр» сәхифәсендә - Төркиядә яшәүче РУШАНИЯ АЛТАЙ*** *6-7 битләр*
- ***Музыкаль тәнәфестә - Туфан Миңнуллинның “Сөбханалла” җыры*** *8 бит*



***2022 ел - Россия халыклары мәдәни мирасы елы***

***Татар кешесе! Нәселеңнең рухы, физик һәм милли сәламәт булуы синең кулыңда. Халкыбызның киләчәге ишле, тәрбияле гаиләдә. Гаилә корганда җавапсыз һәм талымсыз булма...***











## СӨБХАНАЛЛА!

***Туфан Миңнуллин сүзләре***
***Азат Хөсәенов көе***

Сөбханалла, сөбханалла!
Ни гүзәллек бу дөньяда -
Кояш чыга, кояш бата,
Йолдыз калка, таңнар ата!

Сөбханалла, сөбханалла!
Нинди серләр бу дөньяда -
Диңгез ташып, таулар яна,
Ташлар тишеп, чишмә ага.

Сөбханалла, сөбханалла!
Ни гүзәллек бу дөньяда -
Сызылып кына ата таңнар,
Җырлый чишмә, тыңлый таулар.

Сөбханалла, сөбханалла!
Мин бөртек бу дөньяда -
Мәрхәмәтеңнән ташлама,
Мәрхәмәтеңнән ташлама.

** Әлеге җыр Туфан Миңнуллин-*

**“КЫЗЛАР ИЛЕ” ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ**

**Безнең адрес:** Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89 А.

**E-mail: kzlar_ile@mail.ru**

**Шеф-мөхәррир:**
Зөммәрәт Шамил кызы НӘГЫЙМОВА

**Баш мөхәррир:**
Рәмилә Гамил кызы ГАЗИЗУЛЛИНА

**РЕДКОЛЛЕГИЯ**
Зилә ХӘБИБУЛЛИНА
Сөмбел ФАТЫЙХОВА
Лина НИЗАМЕТДИНОВА
Айсылу ГАЙНАНОВА
Гүзәл САБИРОВА
**Чыгарылыш өчен җаваплы:**
“Нур” балалар оешмасы

# 9 ЕЛ БЕРГӘ!

*Аның иҗаты – Идел кебек киң...*
*Фикерләре – Идел кебек тирән...*
*Аның исеме – Идел кебек мәңгелек!*

Тау ягының мәгърур Иделе... Үз милләтен, туган туфрагын, телен һәм иманын рухи бөеклеккә күтәреп, әледән-әле бәргәләнеп-бөтерелеп ирекkә, хакыйкатькә омтылып ага да ага... Идел бит ул...

Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясе җидееллыгын







түгәрәкләде. Разил Исмәгыйль улы Вәлиев, Энгель Нәвап улы Фәттахов, Туфан аганың кызы Әлфия ханым Миңнуллина-Юнысова, Ф.Г.Аитова исемендәге 12 гимназия директоры Илһамия Абделхәй кызы Тимеркәева фатихасы белән башланып киткән Конференция бүген өметле адымнар белән иҗат офыкларын киңәйтә!

7 ел дәвамында Конференция секцияләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советында, “Татмедиа”да, Кәрим Тинчурин театры сәхнәсендә һәм Туфан ага ярдәме белән төзелгән 12 нче гимназиядә узды. Бу 7 елда Конференциядә 3500ләп укучы катнашты, 400 спектакльдән өзекләр каралды...

Конференциянең елда яңартылып, камилләштерелеп торган 6 төрле номинациясендә катнашкан укытучыларның, китапханәчеләрнең һәм укучыларның фәнни-иҗади эшләрен республикабызның күренекле сәнгать әһелләре, галимнәре, журналистлары бәяләде.

“Шигърият. Сөй гомерне, сөй халыкны...” номинациясе жюри әгъзалары: шагыйрьләр – Ләбиб Лерон, Йолдыз Шәрапова, Луиза Янсуар.

“Журналистика. “Кызыл тышлы дәфтәрдән”” номинациясе жюри әгъзалары: Казан федераль университетының гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр Институты профессоры, жюри рәисе Васил Гарифуллин, журналистлар - Эльмира Закирова, Айсылу Галиева, Линар Закиров, Ләйсән Фәйзуллина, Рания Юнысова, галимәләр - Ләйлә

@gymnasium_12tat
#ber_ike_Nur



# ТЕЛ. МИЛЛӘТ. ТУФАН.

һәм сәнгать институты профессоры, жюри рәисе Әлфәт Закирҗанов, Казан федераль университетының Л.Толстой исемендәге филология һәм сәнгать Институты галимнәре - Таһир Гыйләҗев, Нурфия Йосыпова, Гөлфия Гайнуллина, Илһам Гомәров.

“Драма әсәрләре һәм сценарийлар язу бәйгесе. “Театр яктылыкка, нурга илтә!” номинациясе жюри әгъзалары: ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, драматурглар - Мансур Гыйләҗев, Рәдиф Сәгъди, шагыйрәләр - Эльмира Шәрифуллина, Гөлзадә Бәйрәмова.

“Драматургия. “Театр яктылыкка, нурга илтә!” (сәхнәләштерү) номинациясе жюри әгъзалары: Әлфия Миңнуллина-Юнысова, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры артистлары – Нәҗибә Ихсанова, Ирек Баһманов, Әсхәт Хисмәтов, Илдар Хәйруллин, Фәнис Җиһанша, Венера Шакирова, Алмаз Сабирҗанов, Илнур Закиров, Эмиль Талипов, Гүзәл Шакирова, Фәнис Сафин, Айгөл Абашева, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары – Исламия Мәхмүтова, Нуретдин Нәҗмиев, Илгизәр Хәсәнов, Ирек Хафизов, Гөлназ Нәүмәтова, Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт Яшь тамашачы театры артисты Фернат Насибуллин, Казан театр һәм музыка укуханәләре мөгаллиме, телевидение дикторы Инсаф Абдулла, музей мөдире Розалия Чабатова.

“Утырып уйлар уйладым” укытучылар һәм китапханәчеләр номинациясенең “Сандыгымда – Туган тел музее”, китапнамә (буктрейлер) ясау, “Тәҗрибә” мастер-класслар бәйгеләре жюри әгъзалары: “Ак калфак” бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова, галимнәр - Әлфәт Закирҗанов, Таһир Гыйләҗев, Әлфия Мотыйгуллина, Рамилә Сәгъдиева, “Белем.ру” оешмасы директоры Раил Гатауллин, ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләре - Гөларам Җомаголова, Фирдәвес Имамова, Республика балалар китапханәсе директоры урынбасары – Гөлнар Иксанова, шагыйрә Йолдыз







Миңнуллина.

Конференциянең жюри рәисе - Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, халык шагыйре Разил Вәлиев.

Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясе җидееллыгын укучылар үзләре иҗат иткән шигъри юллар белән тәмамлыйсы килә:

Туфан абый! Бик зур рәхмәт Сезгә!
Сезнең иҗат куәт өстәде.
Сез мәңге яшь, һаман исән әле,
Ишетегез! Туфан ҮЛМӘДЕ!

“Мин татар!” дип кычкырасы килә!
Ишетсеннәр иде галәмнәр.
Яңа ачышларга юл саласы,
Башкарасы күпме эшләр бар!

***Конференцияне Оештыру комитеты***

# *КӨМЕШ БЕЛӘЗЕКЛЕ ТУФАН ВАРИСЛАРЫ!*

***“Бәхет өчен бәхетле була белү шарт”.***


***Туфан Миңнуллин***

Гимназиядә Туфан Миңнуллин үзе исән чакта башлап җибәргән күркәм традицияләр бүген дә дәвам итә:

**Туфан Миңнуллин премиясе**

**Туфан Миңнуллин беләзеге**

“Туфан Миңнуллин премиясе” айга бер тапкыр фән-мәгариф, сәнгать яки спорт өлкәсендә казанышларга ирешкән, татар телен камил белгән укучыга бирелә. 2011-2016 елларда премия күләме – 500 сум булса, 2016-2017 уку елыннан бүгенгәчә 1000 сум тәшкил итә. Һәр ел “Соңгы кыңгырау” бәйрәмендә Туфан Миңнуллин исеменнән көмеш беләзекне 11 нче сыйныфны тәмамлаган уку алдынгысына күренекле драматургның гаиләсе – тормыш иптәше Нәҗибә Ихсанова һәм кызы Әлфия Юнысова-Миңнуллина тапшырып килде. Дәвамлы булсын!




***КӨМЕШ БЕЛӘЗЕК ИЯЛӘРЕ***

***2010 - Сибгатуллина Алсу***

***2011 - Чымынтаева Жазгуль***

***2012 - Садриева Алинә***

***2013 - Сираҗиева Алисә***

***2014 - Чыгарылыш булмады***

***2015 - Гәрәфетдинова Камилә***

***2016 - Самиева Надира***

***2017 - Сираҗетдинова Ландыш***

***2018 - Шәвәлиева Алия***

***2019 - Вәлиева Эльвина***

***2020 - Ашит Илайда***

***Зилә ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.***







# *МИН - ТАТАР КЫЗЫ!*

Татар кызы булып тууыма, яшәвемә мин, һичшиксез, әти-әниемә бурычлы. Бүгенге көндә Казан шәһәренең 12 нче гимназиясендә белем алам. Үзем кебек татар кызлары белән аралашам, серләшәм. Шәһәрдә туып үскәнгәме, туган йортымда да, гимназиямдә дә татар мохите булганга сөенеп бетә алмыйм.

Минем белән бергә балалар бакчасына йөргән яшьтәшләремне күрәм дә, аларның үз телләрен начар белүләренә көенеп бетә алмыйм. Менә минем кебек татар телендә белем бирүче гимназиядә укыгыз дип әйтеп тә карыйм. Күрәсең, алар өчен әби- бабаларыбыз теле бик үк якын түгел, ахры.

Әнием Амәл белән әтием Илдарның теләкләре - минем татар кызы булып үсүем, үз телемне, әдәбиятыбызны, мәдәниятебезне белүем. Һәм киләчәктә үзем кебек саф татар телендә сөйләшә алучы балалар үстерүем. Кем белә, бәлки, мин дә милләтемнең йөзек кашы булып китәрмен.

Безнең Тукебыз, русларның Пушкины булгандай, кыргызларның да бөтен дөньяга данлыклы Чыңгыз Айтматов дигән язучысы бар икән. Әйе, аның кебек данлыклы булырга, үз милләтең турында сөйләп, язып бөтен дөньяга шундый матур һәм гади геройлар таратырга язсын иде дип уйлап куям үзем.

Язарга мин дә яратам. Ләкин әле алар бик гади. Әллә нинди проблемалар күтәрә торган хикәяләр түгел. Чыңгыз Айтматов та шулай данлыклы, танылган язучы булып китәрмен, бөтендөнья халкы минем язганнарымны укыр, әсәрләрем буенча спектакльләр, фильмнар төшерелер, 200ләп телгә тәрҗемә ителер, үз халкымны дөнья аренасына чыгарырмын дип минем яшемдә һич кенә дә күз алдына китерә алмагандыр дип уйлыйм.

Киләчәктә мин үземнең татар кызы булып калуыма тәгаен генә ышанам. Әйтәләр бит, татар булып яшәргә түгел, татар булып туарга кирәк диләр. Ә мин нәкъ менә татар кызы булып туганмын. Кечкенәдән үк рәхәтләнеп татарча китаплар, журналлар укыйм, татар телендә барган мультфильмнарны үзем генә карамыйм, кечкенә эне-сеңелләремә дә күрсәтәм. Татарларның үз киносы, үз мультфильмнары, үз әдәбияты, үз сүзе барлыгын белеп үссәннәр дим. Татарча җырлар да өйрәткән булам. Әле кечкенә сеңлемә бишек җыры өйрәтеп маташам. Җырлый гына белми.

Милләтемнең озак-озак еллар бердәм тату булып яшәвен һәр догамда кабул булсын дип телим.

Гаиләбездә булган һәр традиция минем милләтемә бәйле. Һәм алар барысы да күркәм, ихлас. Үзем язам, үзем уйлыйм: шушы бәхет була торгандыр диеп.

Татар кызы нинди була дип сорасалар, мин шушы шигырь юллары белән җавап бирер идем:

*Татар кызы нинди була?*
*Уңган була, җитез була,*
*Кулларыннан аның гөлләр түгелеп тора.*
*Татар кызы тыйнак була, сабыр була,*
*Толымнары биленә төшеп, уйнап тора.*
*Ул аш – суга оста була, була көләч,*
*Һәрбер эше көлеп тора, үзе киткәч.*
*Милләтен ул өзелеп сөя, горурлана,*
*Татар җырын тыңлап, хыяллана.*
*Буе зифа, биле нечкә, үзе уңган,*
*Йөзләренә әллә инде кояш нуры кунган?*



***Ясинә ЗӘБИРОВА, 5 А сыйныфы укучысы***

***Сәлам, сәлам, дуслар! Ниһаять, бу санда - өр-яңа сәхифә! Без аны “МӨҺАҖИРЛӘР” дип атадык. Әлеге сәхифәбезнең 3 үзенчәлеге бар:***

1. ***Биредә без Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез турында бәян итәчәкбез.***
2. ***Жанры - интервью, җәһәт әңгәмә.***
3. ***Төп аралашу интернет аша (социаль челтәрләр, скайп, zoom һ.б.) булачак.***

***Бүген без хәбәрчебез Сөмбел ФАТЫЙХОВАНЫҢ Төркиядә яшәүче милләттәшебез, татар журналисты РУШАНИЯ АЛТАЙ белән әңгәмәсен тәкъдим итәбез! Гыйбрәт алыгыз,***

Рушания Алтай – Төркиядә яшәүче татар журналисты. Чит илдә татарларны танытуда зур эш башкарган милләттәшебез буларак зур кызыксыну уятты. “Тукай” исемендәге мәдәният һәм мәгърифәт үзәгендә матбугат һәм мәдәният бүлеген җитәкли, Сабантуйлар уздыруда башлап йөри. 2004 елда ул Төркиядә беренче тапкыр “21 гасырда Татарстан дип исемләнгән төрекчә журнал да чыгарып ала. Төркия телеканалларында Татарстан һәм татарлар турында егермеләп тапшыру эшләгән. Интернет-радиода татар телендә махсус сәхифә алып барган.

“Журналист буларак аның исеме төрки гавәмдә яхшы таныш. Төркия – Россия арасындагы бәйләнешләр хакында һәм мәгълүмат бирә ул. Аналитик фикерле, тормышка киң, фәлсәфи күзлектән карый белгән каләмдәшем белән аралашу үзе бер бәхет тоелды миңа”, - дип яза “Башкортстан кызы” журналы хәбәрчесе Гөлназ Катоева. Фәүзия Бәйрәмова, Рушания Алтайның танылган тарихчы, дин галиме Рәмзи Морадның ерак оныгы булуы турында да язып чыкты.

Минем дә милләттәшебез, журналист Рушания апа белән якыннанрак танышасым килде. Аңа үземне кызыксындырган сораулар белән мөрәҗәгать иттем.

**- Сез белемегез буенча журналист. Кайда белем алдыгыз? Ул белемнәр кирәк**

## ТАТАР БУЛУЫМ – ГОРУРЛЫК!

- Мин Казан дәүләт университеты журналистика факультетында, аннары Төркиянең Эгәй университеты теле-радио һәм кинематография бүлегендә белем алдым. 2017 елда Казан федераль университетында журналистика буенча магистратура программасын тәмамладым. Алган белемнең, кайда гына булуга карамастан, кирәге чыкмаган чагы булмады. Әлбәттә, мин укыган һөнәри юнәлеш буенча Төркиядә эш табу җиңел түгел. Әмма алган белемем Татарстанның Төркиядәге вәкаләтле вәкиллегендә эшләгәндә дә, Төркиянең төрле PR фирмаларында, хәтта сәүдә ширкәтендә эшләгәндә дә гел кирәк булды. Кулымдагы диплом миңа Төркиядә чыккан“Турецкий берег” журналының баш мөхәррире булып эшләүгә китерде. Шунысы бар: кайда гына эшләсәм дә, мин үзләштергән һөнәремә тугры калдым, беркайчан да журналистиканы ташламадым, кайсы оешмада эшләвемә карамастан Төркия, төркияле татарлар тормышын Татарстан һәм татарлар яшәгән төбәк матбугат органнарында яктыртып бардым. Алган белемнәрем һәм дипломым аркасында мин “Татар-информ” мәгълүмат агентлыгының Төркиядәге хәбәрчесе һәм Татарстан-Төркия тарихында Татарстанның чит илдәге беренче һәм бердәнбер рәсми аккредитацияле журналисты.

**- Чит илләрдә яшәп тә, Татарстан белән тыгыз бәйләнештә торган шәхесләребез бик күп. Надир Дәүләт, Шәмсия Апакай, Гали Акыш Шамил Юлай һәм башкалар. Аларның язмышы шулай булган, ә Сез ни өчен Төркиягә**



# РУШАНИЯ АЛТАЙ КЕМ УЛ?

- Төркиягә мин университетта укырга, дип киттем. Студент вакытында төркияле татар егете Кюршат белән таныштым һәм аңа кияүгә чыгып, бу илдә яшәп калдым.

**- Сез Татарстанда кайда туып–үстегез. Туган якны сагынасызмы?**

- Туган ил, туган җир – иң газиз төшенчәләр. Мин тумышым белән Сарман районыннан. Күңелгә якын әйберләрне сагынмый мөмкин түгел. Хәзер дөньялар бик үзгәрде. Технология бик алга китте. Интернет дөньясында яшибез. Шуның аркасында мин һәр көн туган авылымны, студентлык елларым үткән Казанымны күреп, туганнарым белән аралашып, туган ил яңалыклары белән якыннан танышып торам. Сагыну хисе элеккеге еллардагы кебек түгел.

**- Татар булуыгыз белән горурланасызмы?**

- Татар булуым белән горурланмаган бер көнем дә юк. Милләтебезнең үткәненә, чал тарихына күз атсак, нинди зур, абруйлы дәүләтләр корып яшәгәнлеген күреп горуланмый мөмкин түгел. Туган телебезне алсак, ул иң матур, иң камил телләрнең берсе. Хәтта ЮНЕСКО тарафыннан да дөньядагы иң камил 14 тел арасында картелгән. Әдәбиятыбызны алсак, дөнья классикасыннан бер ким ягын күрмим. Хәтта Нобель премиясенә ия булган язучылардан да күпкә өстен талант иясе әдипләребез бар.

**- Төркиядә яшәүче татарлар белән аралашып яшисезме? Нинди чаралар үткәрәсез?**

- Төркиядә яшәүче татарлар белән аралашып яшибез. Бөтен кеше берберсе белән бик дус, бик тату дип мактанырлык булмаса да, билгеле төркемнәр хәлендә Төркиядә татарлыкны саклауга игътибар бирәбез. Бу җәһәттән, татар язучыларын, шагыйрьләрен искә алу кичәләре, татар халык ашлары буенча бәйгеләр, студентлар арасында КВНнар, “Тукай һәм шигърият” кичәләре оештырдык. Сабан туйлары үткәрәбез. Тукай иҗатына багышланган инша бәйгеләре дә үткәргән чаклар булды. Соңгы ике елда татарча диктант язуны оештырып җибәрдек. Әле күптән түгел генә бүгенге көн татар әдәбияты вәкиле, язучы Гөлсинә Галимуллина белән әдәби очрашу уздырдык. Истанбулда Габдулла Тукай исемендәге парк бар, анда шагыйребезнең һәйкәле урнашкан. Еш кына анда барып киләбез. Гаяз Исхакый, Йосыф Акчураның Истанбулдагы каберләренә сукмакны да суытмыйбыз. Татарстаннан килгән сәнгать төркемнәренең чыгышларын карарга да барабыз. Төркия матбугатында татар тарихы, әдәбияты, фольклоры белән бәйле мәкаләләр бастырабыз, телевидение тапшырулары эшләргә ярдәм итәбез.

**- “Татар-информ” мәгълүмат агентлыгы сайтында материалларыгыз гел басылып тора. Темаларны үзегез тәкъдим итәсезме?**

- Күп очракта темаларны үзем тәкъдим итәм. Кайчак ТИнең җитәкчелеге сораган темаларга да язам. Гадәттә, ТИ җитәкчелеге билгеләгән кагыйдәләргә буйсынып эшлим. Әмма миңа ирек чикләнмәгән. Татарлыкка кагылышлы, билгеле кагыйдәләр кысасында, бөтен теманы яктыртырга тырышам.

**- Төрекләр арасында яшәп татарларның гореф-гадәтләрен саклап буламы?**

- Саклап була. Әмма кулай түгел.

**- Төрек милли ризыкларыннан нәрсәне яратып әзерлисез?**

- Төрек кухнясы - дөньядагы иң бай кухняларның берсе. Андагы бөтен аш-суны да пешереп бетереп булмастыр, мөгаен. Кайберләрен пешерү өчен махсус җайланмалар кирәк. Андый җиһазлар,гадәттә, ресторанннарда гына була. Шулай да, мин төрек шулпаларының барысын да диярлек пешерергә өйрәндем. Көн саен өйдә берәр төрек шулпасы пешерәм. Әйтик, кызыл ясмык шулпасын безнең татарстанлы кунаклар да бик яратып ашый. Төрле үлән ашларын еш пешерәм. Сельдерей, шпинат, баклажан, портулак, кабак, суган-порей кебек үләннәр белән ясалган ашларны бик яратып ашыйбыз...

Аралашуыбызның иң “тәмле” җирендә әңгәмәне тәгәллибез. Дәвамы бар!

***ӘҢГӘМӘДӘШ - Сөмбел ФАТЫЙХОВА.***